ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АЛЕКСЕЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АЛЕКСЕЕВСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

17.07.2020 п.г.т.Алексеевское № 279

**Татарстан Республикасы**
**Алексеевск муниципаль районында**
**Татарстан Республикасы дәүләт телләре**
**турында законнарны гамәлгә ашыру**
**Нигезләмәсенә үзгәреш кертү хакында**

Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районында Татарстан Республикасы дәүләт телләрен һәм башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү өлкәсендә сәясәтне камилләштерү максатларында

**карар бирәм**:

1. «Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районында Татарстан Республикасы дәүләт телләре турындагы законнарны гамәлгә ашыру комиссиясе турында» Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы башкарма комитетының 2020 елның 10 июлендәге 263 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районында Татарстан Республикасы дәүләт телләре турындагы законнарны гамәлгә ашыру Нигезләмәсенә түбәндәге эчтәлекле үзгәреш кертергә:

- Нигезләмәнең 4 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4. Куелган бурычларны үтәү буенча Комиссия:

- Татарстан Республикасы телләре турындагы законнарны үтәү мәсьәләләре буенча тәкъдимнәр әзерли һәм җирле үзидарә органнарына кертә;
- Комиссия эше өчен кирәкле мәгълүматны Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарыннан һәм җирле үзидарә органнарыннан, шулай ук учреждениеләрдән, оешмалардан һәм вазыйфаи затлардан соратып ала;
- муниципаль норматив хокукый актларны үзгәртү турында җирле үзидарә органнарына үз компетенциясе чикләрендә тәкъдимнәр әзерли һәм кертә;
- үз утырышларына чакыра һәм җирле үзидарә органнарының, иҗтимагый берләшмәләр, мәдәният һәм сәнгать оешмалары, фәнни, мәгариф һәм башка оешмалар, сәүдә объектлары вәкилләренең хисапларын тыңлый;
- үз вәкилләрен Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары, иҗтимагый берләшмәләр, мәдәният һәм сәнгать оешмалары, фәнни, мәгариф һәм башка оешмалар, шул исәптән телләр өлкәсендә сәясәтне гамәлгә ашыруга бәйле мәсьәләләр буенча эшчәнлек алып баручы

коммерциягә карамаган оешмалар тарафыннан комиссия компетенциясенә кагылышлы актуаль мәсьәләләр буенча киңәшмәләрдә, конференцияләрдә һәм семинарларда катнашу өчен җибәрә;

- Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы территориясендә җәмгыять тормышының барлык өлкәләрендә Татарстан Республикасы дәүләт телләренең тигез хокуклы һәм оптималь эшләвен, аларның үзара хезмәттәшлеген һәм алга таба үсешен тәэмин итүгә юнәлдерелгән чаралар инициаторы булып тора.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында урнаштырырга

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Алексеевск муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары А.В. Симашевага йөкләргә.

**Башкарма комитет җитәкчесе** **Н.К.Кадыйров**